КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 26 июнь № 466

г. Казань

Татарстан Республикасы вәкилләренең гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган автоном коммерциягә карамаган оешмаларның идарә органнарында катнашу тәртибен раслау турында

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның 10 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы вәкилләренең гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган автоном коммерциягә карамаган оешмаларның идарә органнарында катнашу тәртибен;

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен автоном коммерциягә карамаган оешманың идарә органнарында тәкъдим итү турындагы шартнамәнең үрнәк формасын.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\466.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 26 июнь, 466 нчы карары белән расланды

Татарстан Республикасы вәкилләренең гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган автоном коммерциягә карамаган оешмаларның идарә органнарында катнашу тәртибе

1. Әлеге Тәртип гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган автоном коммерциягә карамаган оешмаларның идарә органнарында Татарстан Республикасы вәкилләренең (алга таба – Татарстан Республикасы вәкилләре) вәкаләтләрен йөкләү, башкару һәм туктату кагыйдәләрен һәм процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы вәкилләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән тиешле эшчәнлек өлкәсендә идарә йөкләнгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (алга таба – башкарма хакимият органы) тәкъдиме буенча билгеләнәләр.

3. Татарстан Республикасы вәкилләренең сан ягыннан составы автоном коммерциягә карамаган оешманың гамәлгә кую документлары белән билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы вәкилләре түбәндәгеләр була ала:

әлеге Тәртип нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләп торучы затлар;

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен автоном коммерциягә карамаган оешмаларның идарә органнарында тәкъдим итү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) һәм әлеге Тәртип нигезендә эш итүче бүтән затлар.

5. Татарстан Республикасы вәкилләренең вәкаләтләре түләүсез башкарыла.

6. Татарстан Республикасы вәкилләре түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

үзләренең хокукларын һәм вазыйфаларын намус һәм акыл белән эш итеп тормышка ашырырга һәм башкарырга;

автоном коммерциягә карамаган оешмалар эшендә шәхсән катнашырга;

автоном коммерциягә карамаган оешмаларның идарә органы карап тикшерүенә чыгарылган мәсьәләләр буенча тавыш бирергә, шул исәптән Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм башкарма хакимият органы йөкләмәләренә таянып эш итеп;

ел саен, 1 майдан да соңга калмыйча, башкарма хакимият органына автоном коммерциягә карамаган оешманың идарә органында үзенең эшчәнлеге турында әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымта нигезендәге форма буенча хисап (электрон формада) тапшырырга.

7. Татарстан Республикасы вәкилләренең түбәндәгеләрне эшләргә хокукы юк:

автоном коммерциягә карамаган оешманың идарә органы эшендә катнашу өчен түләү алырга;

автоном коммерциягә карамаган оешма белән шартнамә мөнсәбәтләрендә торырга;

үзенең вәкаләтләрен бүтән затларга, шул исәптән аларны төп эш урыны буенча алыштыручыларга тапшырырга;

үзенең дәрәҗәсеннән һәм автоном коммерциягә карамаган оешма эшчәнлеге турында алган мәгълүматтан шәхси мәнфәгатьләрдә, шулай ук өченче затлар мәнфәгатьләрендә файдаланырга.

8. Татарстан Республикасы вәкилләренең вәкаләтләре түбәндәге очраклар булганда туктатыла:

Татарстан Республикасы вәкиленең вәкаләтләрне башкарудан азат итү турындагы язма гаризасы;

гражданның юридик хокуклы булмавы, үлеме, аны хәбәре юк яки үлгән дип тану турында суд карары үз көченә керү;

автоном коммерциягә карамаган оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү;

Татарстан Республикасы вәкиле Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәре булган очракта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән чыгару;

Татарстан Республикасына һәм (яки) автоном коммерциягә карамаган оешмага зыян китергән гамәлләр кылу (гамәл кылмау);

Татарстан Республикасы вәкилен җинаять җаваплылыгына тарту.

Татарстан Республикасы вәкиленең вәкаләтләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән башкарма хакимияте органы тәкъдиме буенча туктатыла.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 26 июнь, 466 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен
автоном коммерциягә карамаган оешманың идарә органнарында
тәкъдим итү турындагы шартнамәнең
үрнәк формасы

«___» ____________ 20__ ел

____________________________________________________________ нигезендә эш итүче
____________________________________________________________________ йөзендә
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________________________________________________________________
(шартнамә төзүче Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы исеме)
__________________________________________________, алга таба «Ышанычнамә
бирүче» дип аталучы, бер яктан, һәм
____________________________________________________________________, алга таба
(гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
«Ышанычлы зат» дип аталучы, икенче яктан, әлеге Шартнамәне түбәндәге эш турында төзедек:

## ШАРТНАМӘ ПРЕДМЕТЫ

1. Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен алга таба «Оешма» дип аталучы
______________________________________________________________________________
(автоном коммерциягә карамаган оешманың идарә органы исеме)
органында тәкъдим итү йөкләмәләрен Ышанычнамә бирүче тапшыра, ә Ышанычлы зат үз өстенә ала.

2. Ышанычлы зат Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Оешманы гамәлгә кую документларына һәм әлеге Шартнамәгә таянып тәкъдим итә.

## ЫШАНЫЧЛЫ ЗАТНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

3. Ышанычлы зат түбәндәгеләргә хокуклы:

Ышанычнамә бирүче тарафыннан Оешманың идарә органы карамагына чыгарылган мәсьәләләрне тикшерүне үткәрүне башлап җибәрергә;

Ышанычлы затка йөкләнгән вәкаләтләрне башкару өчен кирәкле мәгълүматны алырга.

4. Ышанычлы зат түбәндәгеләрне үз өстенә ала:

үзенең хокукларын һәм вазыйфаларын намус һәм акыл белән эш итеп тормышка ашырырга һәм башкарырга;

Оешманың идарә органы эшендә шәхсән катнашырга;

Оешманың идарә органы карап тикшерүенә чыгарылган мәсьәләләр буенча тавыш бирергә, шул исәптән Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Ышанычнамә бирүче йөкләмәләренә таянып эш итеп;

ел саен, 1 майдан да соңга калмыйча, Ышанычнамә бирүчегә Оешманың идарә органында үзенең эшчәнлеге турында хисап (электрон формада) тапшырырга.

5. Ышанычлы затның түбәндәгеләргә хокукы юк:

Оешманың идарә органы эшендә катнашу өчен түләү алырга;

Оешма белән шартнамә мөнсәбәтләрендә торырга;

үзенең вәкаләтләрен бүтән затларга, шул исәптән аны төп эш урыны буенча алыштыручыларга тапшырырга;

үзенең дәрәҗәсеннән һәм Оешма эшчәнлеге турында алган мәгълүматтан шәхси мәнфәгатьләрдә, шулай ук өченче затлар мәнфәгатьләрендә файдаланырга.

6. Ышанычлы зат әлеге Шартнамә буенча аңа йөкләнгән бурычларны түләүсез башкара.

## ЫШАНЫЧНАМӘ БИРҮЧЕНЕҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

7. Ышанычнамә бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

Ышанычлы затка Оешманың идарә органы карап тикшерүенә чыгарылган мәсьәләләр буенча тавыш бирүгә нисбәтле йөкләмәләр бирергә;

Ышанычлы затның Оешманың идарә органында катнашуы турында мәгълүмат соратырга һәм алырга.

8. Ышанычнамә бирүче түбәндәгеләрне үз өстенә ала:

Оешманың идарә органындагы башка Татарстан Республикасы вәкилләрен чакырып, Оешманың идарә органы карамагына чыгарылган мәсьәләләрне тикшерүне үз инициативасы белән үткәрергә;

Ышанычлы затка йөкләнгән вәкаләтләрне башкару һәм аның хокукларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны җибәрергә.

## ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

9. Ышанычлы зат Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Шартнамә нигезендә үзенең бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җавап тота.

Ышанычлы затның хокуксыз гамәлләре китергән матди зыян гражданнар законнары нормалары нигезендә капланырга тиеш.

10. Ышанычнамә бирүче тапшырган язма йөкләмәләр нигезендә тавыш биргән булса, Ышанычлы зат тавыш биргән карарларның тискәре нәтиҗәләре өчен җавап тотмый.

## ШАРТНАМӘНЕҢ ҮЗ КӨЧЕНӘ КЕРҮЕ ҺӘМ ГАМӘЛДӘН ЧЫГУЫ

11. Шартнамә ____________________________________ башлап үз көченә керә.

12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнгән нигезләр буенча Татарстан Республикасы вәкиленең вәкаләтләрен туктату турында карар кабул иткән очракта, Шартнамә өзелә.

Ышанычнамә бирүче

Юридик адресы:

___________________________________

___________________________________

Банк реквизитлары:

___________________________________

___________________________________

«___» __________________ 20___ ел.

_____________ /__________________/

(имзасы) (Ф.И.А.и.)

М.У.

Ышанычлы зат

Яшәү урыны адресы:

___________________________________

___________________________________

Паспорт мәгълүматлары:

___________________________________

___________________________________

«___» _____________________ 20___ ел.

____________ /___________________/

(имзасы) (Ф.И.А.и.)

Татарстан Республикасы вәкилләренең гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган автоном коммерциягә карамаган оешмаларның идарә органнарында катнашу тәртибенә
кушымта

Форма

Гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган автоном коммерциягә карамаган оешманың идарә органында Татарстан Республикасы вәкиленең
хисабы

1 бүлек. Гомуми белешмәләр

| | |
|---|---|
| Автоном коммерциягә карамаган оешма исеме | |
| Автоном коммерциягә карамаган оешманың юридик адресы | |
| Автоном коммерциягә карамаган оешманың идарә органы исеме | |
| _________ алып ____________кадәр чорга хисап | |
| Автоном коммерциягә карамаган оешманың идарә органында Татарстан Республикасы вәкиленең Ф.И.Ә.И. | |
| Автоном коммерциягә карамаган оешманың идарә органында Татарстан Республикасы вәкилен билгеләү турында карарның реквизитлары (номеры һәм көне) | |
| Тиешле эшчәнлек өлкәсендә идарә йөкләнгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы белән төзелгән Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен автоном коммерциягә карамаган оешманың идарә органында тәкъдим итү турындагы шартнамәнең реквизитлары (номеры һәм көне) | |

2 бүлек. Соңгы хисап елына автоном коммерциягә карамаган оешманың хуҗалык эшчәнлеге турында белешмәләр

| | |
|---|---|
| Соңгы хисап елына автоном коммерциягә карамаган оешманың керемнәре | |
| Соңгы хисап елына автоном коммерциягә карамаган оешманың чыгымнары | |

3 бүлек. Хисап чорына автоном коммерциягә карамаган оешманың идарә органында Татарстан Республикасы вәкиленең эшчәнлеге

| Идарә органы утырышын үткәрү көне | Идарә органы утырышының көн тәртибендәге мәсьәләләре | Татарстан Республикасы вәкиленең позициясе | Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы биргән күрсәтмәләр | Тавыш бирү нәтиҗәсе |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

4 бүлек. Хисап чорына автоном коммерциягә карамаган оешманың идарә органында Татарстан Республикасы вәкиленең Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, автоном коммерциягә карамаган оешма белән үзара хезмәттәшлеге

| Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы гамәле | Татарстан Республикасы вәкиленең гамәле, гамәл кылмавы, баш тартуы |
|---|---|
| | |

| Татарстан Республикасы вәкиле гамәле | Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының гамәле, гамәл кылмавы, баш тартуы |
|---|---|
| | |

| Татарстан Республикасы вәкиле гамәле | Автоном коммерциягә карамаган оешманың гамәле, гамәл кылмавы, баш тартуы |
|---|---|